СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башлыгы карары**

**22 март 2024 ел** **№ 5**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хәтнә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 13 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хәтнә авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хәтнә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хәтнә авылында гражданнар җыенын

Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Хәтнә авылында Хәтнә авылы, Яшел урам, 18 нче йорт адресы буенча 2024 елның 06 апрелендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 22 ноябрендәге 10 номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

Сез 2024 елда Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналаынр, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- һәйкәлләр кую, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар хөрмәтенә һәйкәлне реконструкцияләү, ремонтлау (Бөек Ватан сугышында катнашучылар исемлеген яңарту)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 22 ноябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан

Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Хәтнә авылы, Яшел урам, 18 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин

СОВЕТ ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ